**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 9 март

№ 132

г. Казань

Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафынна мәк-тәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлгән) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалтуны танырга:

«Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 18 июнь, 420 нче;

«Мәктәпкәчә белем бирә торган белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләрнең мәктәпкәчә белем бирү чыгымнарын финанслар тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1010 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 июнь, 420 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 15 апрель, 229 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\132.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 9 март, 132 нче
карары белән расланды

Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр) бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидияләр шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтү белән бәйле барлыкка килә торган, шул исәптән хезмәт өчен түләү, дәреслекләр һәм уку әсбаплары, белем бирү чаралары, уеннар, уенчыклар сатып алу чыгымнарын кертеп, чыгымнарны каплауга (биналарны тоту һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүне кертмичә) бирелә.

3. Субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы бюджеты акчасының төп идарәчесе булып тора.

4. Субсидияләр шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына Министрлыкка әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга расланган бюджет ассигнованиеләре һәм лимитлары кысаларында бирелә.

5. Субсидия максатчан характерда була һәм башка максатларга юнәлдерелә алмый.

6. Субсидия түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген алып барган;

мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып барырга тиешле лицензияләре булган;

мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча тиешле дәүләт аккредитациясен алган;

субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның беренче көненә:

Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән салымнар, җыемнар һәм бүтән йөкләмәләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурычлары юк;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган.

7. Субсидия алу өчен шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык билгеләгән форма буенча субсидия бирү турында гариза;

шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесенең яки ул вәкаләтләр биргән затның вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе, шәхси эшмәкәрнең шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

салымнар, җыемнар түләү һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетларына бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар юклыгын раслый торган документлар;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юклыкны раслый торган документлар;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юклыкны раслый торган документлар;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаганлыкны раслый торган документлар;

штат расписаниесе күчермәсе;

укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) кабул итү турында боерык реквизитларын, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамәләр реквизитларын күрсәтеп, сыйныфлар (төркемнәр) буенча гариза бирү көнендә шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә укучылар (тәрбияләнүчеләр) исемлеге;

субсидия зурлыгын исәпләү өчен төркемнәр (сыйныфлар) саны, укучылар (тәрбияләнүчеләр) саны турында, белем бирү программалары, территориаль урнашуы, эш режимы, гомуми белем бирү дәрәҗәсе хакында Министрлык билгеләгән форма буенча мәгълүмат.

8. Шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр үз башлангычлары белән түбәндәге документларны тапшыра ала:

федераль законнар нигезендә бирелгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе;

тормышка ашарыла торган төп гомуми белем бирү программаларын дәүләт аккредитацисе турында таныклык күчермәсе;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе.

9. Документлар күчермәләре шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесе, шәхси эшмәкәр имзасы, шулай ук шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

10. Шәхси белем бирү оешмаларыннан, шәхси эшмәкәрләрдән гаризалар һәм документлар кабул итү агымдагы финанс елының 1 октябренә кадәр гамәлгә ашырыла.

11. Шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

12. Министрлык беркетелгән документлары белән гаризалары кабул итеп алуны һәм алар кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә теркәүне гамәлгә ашыра.

13. Министрлык шәхси белем бирү оешмасыннан, шәхси эшмәкәрдән документларны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидияне бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендә карар кабул итә.

14. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәр итү кәгазе тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Министрлык тарафыннан шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә җибәрелә.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта хәбәр итү кәгазендә баш тарту өчен нигезләр күрсәтелә.

15. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмендә тапшырмау);

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

гариза һәм документларны әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән вакытны бозып тапшыру;

шәхси белем бирү оешмаларының, шәхси эшмәкәрләрнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.

16. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр баш тарту өчен нигезләрне бетергәннән соң әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән гаризалар бирү вакыты тәмамланганчы беркетелгән документлары белән кабат гариза бирергә хокуклы.

17. Субсидия бирү Министрлык белән шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган типик форма буенча субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе һәм вакытлары, субсидия бирү шартлары, шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәр гамәлдә башкарылган чыгымнар турында хисап тапшыру вакытлары һәм формасы, субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта аны кире кайтару тәртибе, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия бирү максатларына ирешү белән бәйле бүтәне операцияләрдән тыш, Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавын тикшерүләрне гамәлгә ашыруга шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең ризалыгы күздә тотыла.

18. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

1) шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр өчен:

$$Sd = Nd \times Kd,$$

монда:

Sd – шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр өчен субсидия күләме, сум;

Nd – Татарстан Республикасы законы белән расланган елына бер тәрбияләнүчегә исәпләгәндә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (мәктәпкәчә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы, төре, анда булу вакыты, атнасына эш көннәре саны, тәрбияләнүчеләрнең яшь составына бәйле) һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы, сум;

Kd – шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә тәрбияләнүчеләр саны, кеше;

2) шәхси гомуми белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр өчен:

$$So = (Nd \times Kd) + (No \times Ko),$$

монда:

So – шәхси гомуми белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр өчен субсидия күләме, сум;

Nd – Татарстан Республикасы законы белән расланган елына бер тәрбияләнүчегә исәпләгәндә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (мәктәпкәчә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы, төре, анда булу вакыты, атнасына эш көннәре саны, тәрбияләнүчеләрнең яшь составына бәйле) һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы, сум;

Kd – шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә мәктәпкәчә төркемдә тәрбияләнүчеләр саны, кеше;

No – Татарстан Республикасы законы белән расланган елына бер тәрбияләнүчегә исәпләгәндә гомуми белем бирү оешмаларында (гомуми белем бирү оешмасының территориаль урнашуы, төре, тормышка ашырыла торган белем бирү программасы, гомуми белем дәрәҗәсе, сыйныфлар төрләренә бәйле) һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы, сум;

Ko – шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә укучылар саны, кеше.

19. Министрлык ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 25енә кадәр, агымдагы елның декабре өчен – агымдагы финанс елының 25 декабренә кадәр шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләрнең кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына субсидия күчерә.

Субсидия күчерү килешүдә билгеләнгән сумма кысаларында, әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтүгә тотылган гамәлдәге чыгымнарны раслый торган хисаплар һәм документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

20. Шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр килешүдә каралган тәртиптә, вакытларда һәм формада мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтү белән бәйле барлыкка килгән тотылган гамәлдәге чыгымнар турында, түбәндәге документларны теркәп, Министрлыкка хисап тапшыра:

гамәлдә башкарылган хезмәткәрләр хезмәтенә түләүгә чыгымнар һәм хезмәт өчен түләүгә күчерүләрне раслый торган, шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән, шәхси эшмәкәр тарафыннан расланган беренчел бухгалтер исәбе документлары (эш хакы күчерү, түләү йөкләмәләре һәм бүтән документлар ведомостьлары) күчермәләре;

дәреслекләр һәм уку кулланмалары, укыту чаралары, уеннар, уенчыклар сатып алуга гамәлдәге чыгымнарны раслый торган, шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән, шәхси эшмәкәр тарафыннан расланган счет-фактуралар, товар китерүгә шартнамәләр (контрактлар, килешүләр), товар накладнойлары, башкарылган эшләрне кабул итү актлары, түләү һәм бүтән документлар күчермәләре.

21. Шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтер исәбе алып бара.

22. Шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә субсидия күләме үзгәрү түбәндәге очракларда башкарыла:

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлен туктатып тору;

тиешенчә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясен туктатып тору;

агымдагы финанс елы дәвамында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алу хокукларын тормышка ашыруга дәүләт гарантияләре финанслар белән тәэмин итү нормативлары күләме үзгәрү;

шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә агымдагы финанс елы дәвамында өстәмә төркемнәр (сыйныфлар) ачылу яки агымдагы финанс елы дәвамында төркемнәр (сыйныфлар) ябылу очракларында тәрбияләнүчеләр (укучылар) саны үзгәрү.

23. Шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр коррекцияләнергә тиеш:

22 пунктның икенче һәм өченче абзацлары нигезендә – белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәле туктатылып торган, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча тиешле дәүләт аккредитациясе туктатылып торган чорларны исәпкә кертмичә;

22 пунктның дүртенче абзацы нигезендә – тиешле нормативларны раслый торган Татарстан Республикасы законнары үз көченә кергән көнгә кадәр;

22 пунктның бишенче абзацы нигезендә – шәхси белем бирү оешмасында агымдагы финанс елы дәвамында өстәмә төркемнәр (сыйныфлар) ачылу яки агымдагы финанс елы дәвамында төркемнәр (сыйныфлар) ябылу очракларында тәрбияләнүчеләр (укучылар) саны үзгәрү турында мәгълүмат тапшырылган моменттан.

24. Шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә субсидия бирү түбәндәге очракларда туктатыла:

килешү шартлары бозылгач;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр бетерелгәч, банкрот булгач, яңадан төзелгәч;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булу вакыты тулысынча яки аерым белем бирү программаларына карата тәмамлангач;

дәүләт аккредитациясе вакыты чыккач, дәүләт аккредитациясен тулысынча яки аерым белем бирү программаларына карата тартып алгач.

25. Субсидия күләмен үзгәртү турында яки субсидия бирүне туктату хакында карар боерык рәвешендә әлеге Тәртипнең 22 һәм 24 пунктларында күрсәтелгән шартлар барлыкка килгән вакыттан алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

26. Әлеге Тәртипнең 22 һәм 24 пунктларында күздә тотылган субсидия күләмен үзгәртү яки субсидия бирүне туктату очракларында Министрлык тиешле

карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә шәхси белем бирү оешмасына, шәхси эшмәкәргә карарны кабул итү нигезләрен күрсәтеп, субсидия күләмен үзгәртү турында яки субсидия бирүне туктату хакында хәбәр итә.

27. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Министрлык белән шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр белән килешүгә өстәмә килешү төзелә, анда агымдагы финанс елында субсидия күләме үзгәрү карала.

28. Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң, субсидияләр шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча билгеле булган субсидияне биргәндә билгеләнгән шартларны субсидия алучы бозган очракта тулы күләмдә;

шәхси белем бирү оешмаларында, шәхси эшмәкәрләрдә белем бирү хезмәтләрен күрсәтү белән бәйле барлыкка килгән гамәлдә башкарылган чыгымнар турында хисап тапшырылмаган, хисап тапшыру вакытлары бозылган очракта тулы күләмдә;

субсидия акчасы максатчан файдаланылмавы билгеле булган очракта максатчан файдаланылмаган субсидия күләмендә.

29. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

30. Шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан әлеге әлеге Тәртипнең 28 һәм 29 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылганда Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге чараларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемэнә кире кайтару буенча чара күрә.

31. Законнар нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклауны тикшерүне гамәлгә ашыра.

32. Шәхси белем бирү оешмалары җитәкчеләре, шәхси эшмәкәрләр Министрлыкка тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге һәм субсидияне максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә шәхси җаваплылык тота.

33. Субсидияне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы гамәлгә ашыра.